Яз житте. Барлык жирдә тәртип урнаштырыла. Тер-риториярләрне язын матурлау - буынны берләштерә торган kvркәм традиция. Май бәйрәмнәренә Мордовиянен торле почмаклары чиста һәм матур булып керергә тиеш. Бу эштә бездән kvп нәрсә тора, шуна kvрә урамнарыбызны һәм туган шәһәрләребезне тозекләндерәбез! Чvп-чар-ны жыештырудан тыш, коймаларны әйләндереп алу, ремонтлау һәм палисадникларны буяу начар булмас иде. Яз - клумбаларга чәчәк-ләр, декоратив куаклар һәм агачлар утырту очен бик яхшы вакыт. Яшеллек һаваны кислород белән туендыра, торак пунктларны унайлы һәм кызыклы итә. Әгәр кешеләр vзләре чисталык урнаштырса, йорт яны тирәләрен яшелләндерсә, тәртип сакларга, vсентеләргә сакчыл карарга тырышса, донья ямьләнә, яшәргә жинеләеп китә.

Кагыйдә буларак, чистартылган һәм тозекләндерелгән территорияләрне kvрv теләге фикердәшләрне берләш-терә. Шуна субботниклар оештырабыз. Волонтерлар да эшчеләрне барысын да котеп тормыйлар, капчыкларны алалар да kvл, парклар һәм урманнарны «ваемсызлык продуктлары»ннан арындыралар. Алар кече ватаннарынын чын патриотлары. Эшкуарлар да vз территорияләрен чистартырга, кибет-ләрнен фасадларын тәртипкә китерергә, тәрәзәләрен юарга, урналар урнаштырырга, кашпо да элеп куярга кирәклеген беләләр.

Апрельдә горләтеп республикабызнын торле почмакларында омәләр vткәрәбез. Шулай, Дубенка районы Ломат авылы халкы ой тирәләрен кипкән vленнәрдән, кышкы чvптән жыештырганнар, административ территорияләрендә хезмәт-кәрләре, субботник ясап, тәртип урнаштырганнар. Темников районы Рус Тювеево авылы балалары коче белән дә территорияләрне жыештыру башкарылган. Рустам Кичемасов, Эльвира белән Галя Янбухтиннар, Дамир белән Юнир Дивеевлар, Дамир Утешев, Даша Асаева себеркеләр һәм корәкләр белән коралланып, экологик омә vткәргәннәр. Берничә кон алар vзләре уйный торган мәйданчыкны жыештырганнар. Аннары мәктәпкә йортә торган автобус тукталган кибет тирәсендә тәртип урнаштырганнар. Биредә алар 10 капчык чvп жыйган! Сез ничек уйлыйсыз, алар капчыкларны нәрсә белән тутырган? Шулай-шулай, дорес уйлыйсыз - исерткеч шешәләрдән алып банкларга кадәр жыйганнар. Ничегрәк килеп чыга сон: олкәннәр пычрата, ә балалар жыя!

- Хормәтле авыл халкы, чисталыкны һәм тәртипне саклавыгызны сорыйбыз! Машина тәрәзәсеннән чvп ташламагыз, тиешсез урыннарда калдыклар белән пакетлар калдырмагыз! Балаларга тырышлыклары һәм доньяны чистарак итv теләге очен, ә эти-әниләренә - шундый лаеклы кешеләрне тәрбияләгән очен зур рәхмәт! - ди Ирина

Николаевна Асаева, Рус Тювеево авылы жирлеге башлыгы урынбасары.

Н.Хәлил